**МИНИСТЕРСТВО ФИНАНСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФИНАНС МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

27.12.2016 г. Казань № 02-157

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 30.12.2015 ел, № 02-144 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы бюджетына һәм Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджетына кагылышлы өлешендә Россия Федерациясе бюджет классификациясен куллану тәртибен билгеләү, аныклау һәм тәгаенләштерү турында күрсәтмәләргә үзгәрешләр кертү хакында

Боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 30.12.2015 ел, № 02-144 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы бюджетына һәм Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджетына кагылышлы өлешендә Россия Федерациясе бюджет классификациясен куллану тәртибен билгеләү, аныклау һәм тәгаенләштерү турында күрсәтмәләргә (Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 30.03.2016 ел, № 02-32, 29.06.2016 ел, № 02-73, 30.09.2016 ел, № 02-116 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) үзгәрешләрне (кушымта итеп бирелә) расларга.

Министр Р.Р.Гайзатуллин

Татарстан Республикасы
Финанс
министрлыгының
«27 декабрь» 2016 ел
№ 02-157
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 30.12.2015 ел, № 02-144 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы бюджетына һәм Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджетына кагылышлы өлешендә Россия Федерациясе бюджет классификациясен куллану тәртибен билгеләү, аныклау һәм тәгаенләштерү турында күрсәтмәләргә кертелә торган үзгәрешләр

1. «Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджеты чыгымнары исемлеге һәм аларны тиешле максатчан статьяларга кертү кагыйдәләре» 2 пунктта:

а) «2020 елга кадәр Татарстан Республикасында сәламәтлек саклау өлкәсен үстерү» дәүләт программасы» 2.1 пунктчасында:

«01 1 04 00000 «Беренчел медицина-санитария ярдәмен үстерү, шул исәптән авылда яшәүчеләр өчен. Чирләрне һәм патологик халәтләрне һәм аларның үсеш алу куркынычы факторларын иртәрәк ачыклау системасын үстерү, халыкка медицина тикшерүләрен һәм диспансеризация үткәрүне кертеп, шул исәптән балаларга» төп чарасы» максатчан статьясында «-97100 Ведомство учреждениеләре эшчәнлеген тәэмин итү» чыгымнар юнәлеше атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- 97100 Сәламәтлек саклау өлкәсендә ведомство учреждениеләре эшчәнлеген тәэмин итү»;

«01 2 06 00000 «Яман шеш авыруларыннан интегүче сырхауларга медицина ярдәме күрсәтү системасын камилләштерү. Сырхауларны өч дәрәҗәдә маршрутизацияләү. Дәвалап җиткерүне һәм реабилитацияләүне оештыру» максатчан статьясы текстын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге максатчан статья буенча чыгымнарның түбәндәге юнәлешләре буенча кече программаны тормышка ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла:

- 97050 Сәламәтлек саклау учреждениеләрен матди-техник яктан тәэмин итү

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча сәламәтлек саклау учреждениеләрен матди-техник яктан тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

- 97100 Сәламәтлек саклау өлкәсендә ведомство учреждениеләре эшчәнлеген тәэмин итү

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча сәламәтлек саклау өлкәсендә ведомство учреждениеләрен карап тотуга һәм аларның эшчәнлеген тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.»;

«01 2 09 00000 «Башка авырулардан интегүче сырхауларга медицина ярдәмен күрсәтү системасын камилләштерү. Дәвалап җиткерүне һәм реабилитацияләүне оештыру» максатчан статьясы текстын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге максатчан статья буенча чыгымнарның түбәндәге юнәлешләре буенча кече программаны тормышка ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла:

- 54220 2014 – 2016 елларда Украина гражданнарына һәм гражданлыксыз затларга Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары карамагындагы медицина оешмалары тарафыннан федераль бюджет средстволары хисабына медицина ярдәме күрсәтүгә бәйле чыгымнарны, шулай ук әлеге затларга эпидемия күрсәткечләре буенча профилактика прививкалары календарена кертелгән профилактика прививкаларын ясау чыгымнарын компенсацияләү

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча 2014 – 2016 елларда Украина гражданнарына һәм гражданлыксыз затларга Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары карамагындагы медицина оешмалары тарафыннан медицина ярдәме күрсәтүгә бәйле чыгымнарны, шулай ук әлеге затларга эпидемия күрсәткечләре буенча профилактика прививкалары календарена кертелгән профилактика прививкаларын ясау чыгымнарын компенсацияләүгә федераль бюджеттан башка бюджетара трансфертлар хисабына хәл ителә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга башка бюджетара трансфертларның керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «2014 – 2016 елларда Украина гражданнарына һәм гражданлыксыз затларга Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары карамагындагы медицина оешмалары тарафыннан федераль бюджет средстволары хисабына медицина ярдәме күрсәтүгә бәйле чыгымнарны, шулай ук әлеге затларга эпидемия күрсәткечләре буенча профилактика прививкалары календарена кертелгән профилактика прививкаларын ясау чыгымнарын компенсацияләүгә Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар» 000 2 02 04087 02 0000 151 коды буенча чагылдырыла.

- 97030 Сәламәтлек саклау өлкәсендә башка чаралар

- 97050 Сәламәтлек саклау өлкәсе учреждениеләрен матди-техник яктан тәэмин итү

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча сәламәтлек саклау өлкәсе учреждениеләрен матди-техник яктан тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

- 97100 Сәламәтлек саклау өлкәсендә ведомство учреждениеләре эшчәнлеген тәэмин итү

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча сәламәтлек саклау өлкәсендә ведомство учреждениеләрен карап тотуга һәм аларның эшчәнлеген тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

- 97150 Махсус медицина ярдәме белән идарә итү»;

«01 2 10 00000 «Югары технологияле медицина ярдәмен камилләштерү, дәвалауның нәтиҗәле яңа ысулларын үстерү» төп чарасы» максатчан статьясына түбәндәге чыгымнар юнәлешен өстәргә:

«- R4020 Россия Федерациясе гражданнарына мәҗбүри медицина иминиятләштерүенең база программасына кертелмәгән югары технологияле медицина ярдәмен күрсәтүгә финанслашыла торган чыгымнар

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча Татарстан Республикасы бюджеты средстволары хисабына, Россия Федерациясе гражданнарына мәҗбүри медицина иминиятләштерүенең база программасына кертелмәгән югары технологияле медицина ярдәмен күрсәтүгә федераль бюджеттан субсидияләрне финанслашуга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.»;

«01 4 04 00000 «Балаларга махсус медицина ярдәмен үстерү» төп чарасы» максатчан статьясында «-97100 ведомство учреждениеләре эшчәнлеген тәэмин итү» чыгымнар атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- 97100 Сәламәтлек саклау өлкәсендә ведомство учреждениеләре эшчәнлеген тәэмин итү»;

«01 7 03 00000 «Медицина хезмәткәрләренең аерым категорияләренә социаль ярдәм» төп чарасы» максатчан статьясында «- 16000 Медицина хезмәткәрләренә бер тапкыр түләнелә торган компенсация түләүләре» чыгымнар юнәлеше атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- 16000 Татарстан Республикасы бюджеты средстволары хисабына медицина хезмәткәрләренә бер тапкыр түләнелә торган компенсация түләүләре»:

б) «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында мәгариф һәм фәнне үстерү» дәүләт программасы» 2.2. пунктчасында:

«02 2 05 00000 «Гомуми белем бирү системасында курслар үткәрү һәм кадрларның профессиональ әзерлеген үстерү» төп чарасы» максатчан статьясына түбәндәге чыгымнар юнәлешен өстәргә:

«-R4980 «2016 – 2020 елларга мәгарифне үстерүнең федераль максатчан программасы чараларын финанс ягыннан тәэмин итүгә финанслашыла торган чыгымнар

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча Татарстан Республикасы бюджеты средстволары хисабына, 2016 – 2020 елларга мәгарифне үстерүнең федераль

максатчан программасы чараларын финанс ягыннан тәэмин итүгә федераль бюджеттан субсидияләрне финанслашуга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла»;

«02 2 09 00000 «Гомуми белем бирү системасын модернизацияләү, мәгариф өлкәсендә чаралар үткәрү» төп чарасы» максатчан статьясында:

«- 43690 Әдәбият, сәнгать, мәгариф, басма массакүләм мәгълүмат чаралары, фән һәм техника өлкәсендә премияләр һәм дәүләт алдындагы аерым казанышлар өчен башкача бүләкләүләр» чыгымнар юнәлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- 43690 Әдәбият һәм сәнгать, мәгариф, басма массакүләм мәгълүмат чаралары, фән һәм техника өлкәсендә премияләр һәм дәүләт алдындагы аерым казанышлар өчен башкача бүләкләүләр

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча әдәбият һәм сәнгать, мәгариф, басма массакүләм мәгълүмат чаралары, фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы премияләрен бирүгә һәм дәүләт алдындагы аерым казанышлар өчен башкача бүләкләүләргә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.»;

түбәндәге чыгымнар юнәлешен өстәргә:

«- R4980 2016 – 2020 елларга мәгарифне үстерүнең федераль максатчан программасы чараларын финанс ягыннан тәэмин итүгә финанслашыла торган чыгымнар

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча, Татарстан Республикасы бюджеты средстволары хисабына, 2016 – 2020 елларга мәгарифне үстерүнең федераль максатчан программасы чараларын финанс ягыннан тәэмин итүгә федераль бюджеттан субсидияләрне финанслашуга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.»;

«02 3 01 00000 «Дәүләт мәгариф оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне оештыру» төп чарасы» максатчан статьясы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«02 3 01 00000 «Дәүләт мәгариф оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне оештыру» төп чарасы»;

«02 4 03 00000 «Һөнәри белем бирү системасын модернизацияләү, мәгариф өлкәсендә чаралар үткәрү» төп чарасы» максатчан статьясына түбәндәге чыгымнар юнәлешен өстәргә:

«- 54630 Федераль бюджет средстволары хисабына, 2019 елда Казан шәһәрендә «Ворлдскиллс» стандартлары буенча һөнәри осталык буенча дөнья чемпионатына әзерләнү буенча төп чараларны тормышка ашыру

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча 2019 елда Казан шәһәрендә «Ворлдскиллс» стандартлары буенча һөнәри осталык буенча дөнья чемпионатына әзерләнү буенча төп чараларны тормышка ашыруга федераль бюджеттан башка бюджетара трансфертлар хисабына хәл ителә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләрнең керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «2019 елда Казан шәһәрендә «Ворлдскиллс» стандартлары буенча һөнәри осталык буенча дөнья чемпионатына әзерләнү буенча төп чараларны тормышка ашыруга Татарстан Республикасы бюджетына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар» 000 2 02 04125 02 0000 151 коды буенча чагылдырыла.»;

в) «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм» дәүләт программасы» 2.3. пунктчасында «Федераль һәм республика законнарында билгеләнгән гражданнарның аерым категорияләренә социаль ярдәм чараларын күрсәтү» төп чарасы «03 1 01 00000» максатчан статьясында «- 05230 Татарстан Республикасы бюджеты хисабына, җирләү буенча хезмәт күрсәтүләрнең гарантияләнгән исемлеге буенча чыгымнарны каплауга һәм җирләүгә социаль пособие түләү» чыгымнар юнәлеше атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- 05230 Җирләү буенча хезмәт күрсәтүләрнең гарантияләнгән исемлеге буенча чыгымнарны каплауга һәм җирләүгә социаль пособие түләү»;

г) «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында яшәүчеләрнең сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү» дәүләт программасы» 2.4. пунктчасында:

«04 1 01 00000 «Яшь гаиләләргә эконом-класс торагын сатып алуга социаль түләүләр бирү» төп чарасы» максатчан статьясына чыгымнарның түбәндәге юнәлешен өстәргә:

«- R0200 Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итүгә финанслашыла торган чыгымнар

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча, Татарстан Республикасы бюджеты средстволары хисабына, яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итүгә федераль бюджеттан субсидияләрне финанслашуга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.»;

«2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында яшәүчеләрне сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәте күрсәтүләр белән тәэмин итү» дәүләт программалары кысаларында социаль һәм инженерлык инфраструктурасына бюджет инвестицияләре һәм капиталь ремонт» кече программасы» 04 К 00 00000» максатчан статьясы текстын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге максатчан статья буенча чыгымнарның әлеге юнәлешләре буенча кече программаны тормышка ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла:

- 03580 «Развитие» сәнәгать паркы территориясендә һәм Чаллы шәһәре сәнәгать зонасында инфраструктура булдыру

- 03581 «Моношәһәрләрне үстерү фонды» коммерциясез оешма средстволары хисабына Чаллы шәһәрендә «Развитие» сәнәгать паркы территориясендә инженерлык инфраструктурасын булдыру

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча Чаллы шәһәрендә «Развитие» сәнәгать паркы территориясендә инженерлык инфраструктурасы булдыруга «Моношәһәрләрне үстерү фонды» коммерциясез оешмасы средстволары хисабына хәл ителә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга средстволарның Татарстан Республикасы бюджетына керүе «Моношәһәрләрне үстерү фонды» коммерциясез оешмасыннан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына, иң катлаулы социаль-икътисадый хәлдәге моношәһәрләр икътисадын модернизацияләүгә юнәлдерелгән инвестицион проектларны тормышка ашыру максатыннан чыгып, дәүләт (муниципаль) милкендәге инфраструктура объектларын төзүгә һәм (яки) реконструкцияләүгә җибәрелә торган акчалар» 000 2 04 02040 02 0000 180 колы буенча чагылдырыла.

- 03582 Татарстан Республикасы бюджеты средстволары хисабына, Чаллы шәһәрендә «Развитие» сәнәгать паркы территориясендә инженерлык инфраструктурасын булдыру

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча Чаллы шәһәрендә «Развитие» сәнәгать паркы территориясендә инженерлык инфраструктурасын булдыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

- 03590 «Зеленодольск» сәнәгать мәйданчыгы территориясендә инфраструктура булдыру

- 03592 «Моношәһәрләрне үстерү фонды» коммерциясез оешмасы средстволары хисабына «Зеленодольск» сәнәгать мәйданчыгы территориясендә инженерлык инфраструктурасын булдыру

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча «Зеленодольск» сәнәгать мәйданчыгы территориясендә инженерлык инфраструктурасын булдыруга «Моношәһәрләрне үстерү фонды» коммерциясез оешмасы средстволары хисабына хәл ителә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга средстволарның Татарстан Республикасы бюджетына керүе «Моношәһәрләрне үстерү фонды» коммерциясез оешмасыннан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына, иң катлаулы социаль-икътисадый хәлдәге моношәһәрләр икътисадын модернизацияләүгә юнәлдерелгән инвестицион проектларны тормышка ашыру максатыннан чыгып, дәүләт (муниципаль) милкендәге инфраструктура объектларын төзүгә һәм (яки) реконструкцияләүгә җибәрелә торган акчалар» 000 2 04 02040 02 0000 180 коды буенча чагылдырыла.

- 03594 Татарстан Республикасы бюджеты средстволары хисабына «Зеленодольск» сәнәгать мәйданчыгы территориясендә инженерлык инфраструктурасын булдыру

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча «Зеленодольск» сәнәгать мәйданчыгы территориясендә инженерлык инфраструктурасын булдыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

- 14150 Торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә чаралар

- 14160 Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә парклар һәм скверлар булдыру һәм аларны төзекләндерү чараларын тормышка ашыру

- 50210 Федераль бюджет средстволары хисабына, 2015 – 2020 елларга «Торак» федераль максатчан программасының «Россия Федерациясе субъектларының торак төзелешен үстерү программаларына этәргеч бирү» кече программасы чараларын тормышка ашыру

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча 2015 – 2020 елларга «Торак» федераль максатчан программасының «Россия Федерациясе субъектларының торак төзелешен үстерү программаларына этәргеч бирү» кече программасы чараларын тормышка ашыруга федераль бюджеттан субсидияләр хисабына хәл ителә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга субсидияләрнең керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Федераль максатчан программаларны тормышка ашыру өчен бюджетларга субсидияләр» 000 2 02 02051 00 0000 151 керемнәр төренең тиешле коды буенча чагылдырыла.

- 72310 Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) милкенең социаль һәм инженерлык инфраструктурасына бюджет инвестицияләре һәм капиталь ремонт.

- 72350 Татарстан Республикасында социаль тармакларны һәм иҗтимагый инфраструктураны үстерү

- 72360 «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы дәүләт торак фонды» коммерциясез оешмасына торак төзелеше буенча уставтагы эшчәнлеген хәл итүгә субсидияләр

- R0210 2015 – 2020 елларга «Торак» федераль максатчан программасының «Россия Федерациясе субъектларының торак төзелешен үстерү программаларына этәргеч бирү» кече программасы чараларын тормышка ашыруга финанслашыла торган чыгымнар

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча, Татарстан Республикасы бюджеты средстволары хисабына, 2015 – 2020 елларга «Торак» федераль максатчан программасының «Россия Федерациясе субъектларының торак төзелешен үстерү программаларына этәргеч бирү» кече программасы чараларын тормышка ашыруга федераль бюджеттан субсидияләрне финанслашуга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.»;

«04 Э 00 00000 «Торак-коммуналь хуҗалыкта энергияне сак тоту һәм энергетиканың нәтиҗәсен арттыру» кече программасы» максатчан статьясы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«04 Э 00 00000 «Энергияне сак тоту һәм энергетиканың нәтиҗәсен арттыру» кече программасы;

«04 Э 01 00000 «Торак фонды һәм социаль өлкә объектларында энергияне сак тоту чараларын үткәрү» төп чарасы» максатчан статьясында «- 96010 Татарстан Республикасы бюджеты средстволары хисабына, күп фатирлы йортларны капиталь ремонтлау чараларын тәэмин итү» чыгымнар юнәлеше атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- 96010 Күп фатирлы йортларны капиталь ремонтлау чараларын тәэмин итү»;

д) «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында мәдәниятне үстерү» дәүләт программасы» 2.8. пунктчасына түбәндәген эчтәлектәге максатчан статьяны өстәргә:

«08 Э 00 00000 «Энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәсен арттыру» кече программасы

Әлеге максатчан статья буенча түбәндәге төп чара буенча кече программаны тормышка ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла:

08 Э 01 00000 «Мәдәният учреждениеләрендә энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәсен арттыру» төп чарасы

Әлеге максатчан статья буенча чыгымнарның түбәндәге юнәлеше буенча төп чараны тормышка ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла:

- 44100 Мәдәният һәм кинематография өлкәсендә чаралар

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча мәдәният һәм кинематография өлкәсендә чараларны тормышка ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.»;

е) «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен, физик культура һәм спортны үстерү» дәүләт программасы» 2.10. пунктчасында

«10 1 00 00000 «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен, физик культура һәм спортны үстерү» кече программасы» максатчан статьясының атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10 1 00 00000 «2014 – 2020 елларга яшьләр сәясәтен, физик культура һәм спортны үстерү» кече программасы»;

«10 2 00 00000 «2014 – 2020 елларга балалар һәм яшьләр ялын, аларның сәламәтлеген ныгытуны һәм мәшгульлеген оештыру» кече программасы» максатчан статьясын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10 2 00 00000 «2014 – 2020 елларга балалар һәм яшьләр ялын оештыру» кече программасы

Әлеге максатчан статья буенча түбәндәге төп чара буенча кече программаны тормышка ашыруга Татарстан республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла:

10 2 01 00000 «Балалар һәм яшьләр ялын, аларның сәламәтлеген ныгытуны оештыру һәм савыктыру нәтиҗәсен арттыру өчен шартлар тудыру» төп чарасы

Әлеге максатчан статья буенча чыгымнарның түбәндәге юнәлешләре буенча төп чараны тормышка ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла:

- 21320 Ял, сәламәтлек ныгытуны оештыру чаралары

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча ял, сәламәтлек ныгытуны оештыру чараларын тормышка ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла:

- 54570 Федераль бюджет средстволары хисабына, тормышта авыр хәлләрдә калган балалар ялына һәм сәламәтлеген ныгытуга бәйле чараларны финанс ягыннан тәэмин итү

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча тормышта авыр хәлләрдә калган балалар ялына һәм сәламәтлеген ныгытуга бәйле чараларны финанс ягыннан тәэмин итүгә федераль бюджеттан башка бюджетара трансфертлар хисабына хәл ителә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга башка бюджетара трансфертларның керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Тормышта авыр хәлләрдә калган балалар ялына һәм сәламәтлеген ныгытуга бәйле чараларны финанс ягыннан тәэмин итүгә бюджетларга тапшырыла торган бюджетара трансфертлар» 000 2 02 04118 00 0000 151 керемнәр төренең тиешле кодлары буенча чагылдырыла.»;

«10 3 00 00000 «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының авыл яшьләре» кече программасы» максатчан статьясы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10 3 00 00000 «2014 – 2020 елларга авыл яшьләре» кече программасы»;

«10 Ф 00 00000 «Футбол буенча 2018 елгы дөнья чемпионатын үткәрүгә әзерләнү» кече программасы» максатчан статьясына түбәндәге чыгымнар юнәлешләрен өстәргә:

«- 54580 Федераль бюджет средстволары хисабына, 45000 тамашачыга исәпләнгән футбол стадионын (Татарстан Республикасы, Казан ш.) инженерлык системалары белән үлән түшәмәсе белән тәэмин итү чараларын тормышка ашыру

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча 45000 тамашачыга исәпләнгән футбол стадионын (Татарстан Республикасы, Казан ш.) инженерлык системалары белән үлән түшәмәсе белән тәэмин итү чараларын тормышка ашыруга федераль бюджеттан башка бюджетара трансфертлар хисабына хәл ителә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга Татарстан Республикасы бюджетына башка бюджетара трансфертларның керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «45000

тамашачыга исәпләнгән футбол стадионын (Татарстан Республикасы, Казан ш.) инженерлык системалары белән үлән түшәмәсе белән тәэмин итү чараларын тормышка ашыруга Татарстан Республикасы бюджетына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар» 000 2 02 04119 02 0000 151 коды буенча чагылдырыла.

- 55300 Федераль бюджет средстволары хисабына, Россия Федерациясендә 2018 елда FIFA футбол буенча дөнья чемпионатын үткәрүгә әзерләнү буенча спорт ярышларына әзерләнү һәм аларны үткәрү өчен вакытлыча билгеләнештәге һәм (яки) ярдәмче билгеләнештәге җиһазлар һәм корылмалар белән тәэмин итүгә, монтажлау һәм сүтүгә бәйле чараларны тормышка ашыру

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча Россия Федерациясендә 2018 елда FIFA футбол буенча дөнья чемпионатын үткәрүгә әзерләнү буенча спорт ярышларына әзерләнү һәм аларны үткәрү өчен вакытлыча билгеләнештәге һәм (яки) ярдәмче билгеләнештәге җиһазлар һәм корылмалар белән тәэмин итүгә, монтажлау һәм сүтүгә бәйле чараларны тормышка ашыруга федераль бюджеттан башка бюджетара трансфертлар хисабына хәл ителә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга Татарстан Республикасы бюджетына башка трансфертларның керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Россия Федерациясендә 2018 елда FIFA футбол буенча дөнья чемпионатын үткәрүгә әзерләнү буенча спорт ярышларына әзерләнү һәм аларны үткәрү өчен вакытлыча билгеләнештәге һәм (яки) ярдәмче билгеләнештәге җиһазлар һәм корылмалар белән тәэмин итүгә, монтажлау һәм сүтүгә бәйле чараларны финанслашуга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар» 000 2 02 04127 02 0000 151 коды буенча чагылдырыла.»;

ж) «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасы» 2.11. пунктчасында:

«11 2 00 00000 «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» кече программасы» максатчан статьясы атамасында «2014 – 2020 елларга» дигән сүзләрне «2014 – 2016 елларга» дигән сүзләргә алыштырырга;

«11 2 01 00000 «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлек секторы күләмен арттыру» төп чарасы» максатчан статьясына түбәндәге чыгымнар юнәлешләрен өстәргә:

«- R1110 Россия Федерациясе субъектларының дәүләт милкендәге объектларына капитал салуларны финанслашу

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча, Татарстан Республикасы бюджеты средстволары хисабына, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт милкендәге объектларына капитал салуларга федераль бюджеттан субсидияләрне финанслашу максатыннан чыгып, Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

- R4450 Яшьләр арасында эшмәкәрлеккә дәүләт ярдәменә финанслашыла торган чыгымнар

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча, Татарстан Республикасы бюджеты средстволары хисабына, яшьләр арасында эшмәкәрлеккә дәүләт ярдәменә федераль бюджеттан субсидияләрне финанслашу максатыннан Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.»;

з) «12 3 02 00000 «Татарстан Республикасында мәгълүмати киңлеккә һәм массакүләм коммуникацияләргә дәүләт ярдәме һәм аларны үстерү» төп чарасы» максатчан статьясында «2014 – 2020 елларга «Ачык Татарстан» Татарстан Республикасында мәгълүмати һәм коммуникация технологияләрен үстерү» дәүләт программасы» 2.12. пунктчасында «- 47510 «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика дәүләт хакимияте органнарының норматив актлары җыентыгы» журналы редакциясе» автоном коммерциясез оешмасына субсидияләр» чыгымнар юнәлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- 47510 «Татарстан Республикасының законнар җыентыгы» журналы редакциясе» автоном коммерциясез оешмасына субсидияләр

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча Татарстан Республикасының законнар җыентыгы» журналы редакциясе» автоном коммерциясез оешмасына субсидияләр бирүгә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.»;

и) «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы транспорт системасын үстерү» дәүләт программасы» 2.13. пунктчасында «13 6 01 00000 «Гомуми файдаланудагы автомобиль юллары челтәрен үстерү» төп чарасы» максатчан статьясы текстын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Әлеге максатчан статья буенча чыгымнарның түбәндәге юнәлешләре буенча төп чараны тормышка ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла:

- 03150 Юл хуҗалыгын карап тоту һәм аның белән идарә итү

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча юл фондын карап тоту һәм аның белән идарә итүгә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

- 03550 Татарстан Республикасы автомобиль юллары челтәрен камилләштерү, үстерү һәм саклау

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча Татарстан Республикасы автомобиль юллары челтәрен камилләштерү, үстерү һәм саклауга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

- 03580 «Развитие» сәнәгать паркы һәм Чаллы шәһәре сәнәгать зонасы территориясендә инфраструктура булдыру

- 03583 «Моношәһәрләрне үстерү фонды» коммерциясез оешма средстволары хисабына, Чаллы шәһәре сәнәгать зонасында гомуми файдаланудагы юл инфраструктурасын булдыру

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча Чаллы шәһәре сәнәгать зонасында гомуми файдаланудагы юл инфраструктурасын булдыруга «Моношәһәрләрне үстерү фонды» коммерциясез оешмасы средстволары хисабына хәл ителә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла

Әлеге максатларга средстволарның Татарстан Республикасы бюджетына керүе «Моношәһәрләрне үстерү фонды» коммерциясез оешмасыннан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына, иң катлаулы социаль-икътисадый хәлдәге моношәһәрләр икътисадын модернизацияләүгә юнәлдерелгән инвестицион проектларны тормышка ашыру максатыннан чыгып, дәүләт (муниципаль) милкендәге инфраструктура объектларын төзүгә һәм (яки) реконструкцияләүгә җибәрелә торган акчалар» 000 2 04 02040 02 0000 180 коды буенча чагылдырыла.

- 03584 Татарстан Республикасы бюджеты средстволары хисабына Чаллы шәһәре сәнәгать зонасында гомуми файдаланудагы юл инфраструктурасын булдыру

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча Чаллы шәһәре сәнәгать зонасында гомуми файдаланудагы юл инфраструктурасын булдыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла

- 03590 «Зеленодольск» сәнәгать мәйданчыгы территориясендә инфраструктура булдыру

- 03591 «Моношәһәрләрне үстерү фонды» коммерциясез оешмасы средстволары хисабына «Зеленодольск» сәнәгать мәйданчыгы территориясендә инженерлык инфраструктурасын булдыру

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча «Зеленодольск» сәнәгать мәйданчыгы территориясендә инженерлык инфраструктурасын булдыруга «Моношәһәрләрне үстерү фонды» коммерциясез оешмасы средстволары хисабына хәл ителә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга средстволарның Татарстан Республикасы бюджетына керүе «Моношәһәрләрне үстерү фонды» коммерциясез оешмасыннан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына, иң катлаулы социаль-икътисадый хәлдәге моношәһәрләр икътисадын модернизацияләүгә юнәлдерелгән инвестицион проектларны тормышка ашыру максатыннан чыгып, дәүләт (муниципаль) милкендәге инфраструктура объектларын төзүгә һәм (яки) реконструкцияләүгә җибәрелә торган акчалар» 000 2 04 02040 02 0000 180 коды буенча чагылдырыла.

- 03593 Татарстан Республикасы бюджеты средстволары хисабына, «Зеленодольск» сәнәгать мәйданчыгы территориясендә гомуми файдаланудагы юл инфраструктурасын булдыру

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча «Зеленодольск» сәнәгать мәйданчыгы территориясендә гомуми файдаланудагы юл инфраструктурасын булдыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла

- 54200 Федераль бюджет средсвтолары хисабына, юл хуҗалыгы өлкәсендә төбәк программалар чараларын тормышка ашыру, дәүләти-хосусый партнерлык механизмнарын куллану нигезендә тормышка ашырыла торган проектларны һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары нигезендә тиңдәшсез ясалма юл корылмаларын төзү, реконструкцияләү һәм ремонтлауны кертеп

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча юл хуҗалыгы өлкәсендә төбәк программалар чараларын тормышка ашыруга, дәүләти-хосусый партнерлык механизмнарын куллану нигезендә тормышка ашырыла торган проектларны һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары нигезендә тиңдәшсез ясалма юл корылмаларын төзү, реконструкцияләү һәм ремонтлауны кертеп, федераль бюджеттан бюджетара трансфертлар хисабына хәл ителә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга башка бюджетара трансфертларның Татарстан Республикасы бюджетына керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Юл хуҗалыгы өлкәсендә төбәк программалар чараларын тормышка ашыруга, дәүләти-хосусый партнерлык механизмнарын куллану нигезендә тормышка ашырыла торган проектларны һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары нигезендә тиңдәшсез ясалма юл корылмаларын төзү, реконструкцияләү һәм ремонтлауны кертеп, Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар» 000 2 02 04095 02 0000 151 коды буенча чагылдырыла.

- 72350 Татарстан Республикасында социаль тармакларны һәм иҗтимагый инфраструктураны үстерү»;

л) «2013 – 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасы» 2.14. пунктчасында:

«14 1 02 00000 «Күпьеллык үсемлекләрне утырту һәм карауга ярдәм итү» төп чарасы» максатчан статьясында «- R0340 «Күпьеллык җимеш һәм җиләк агачларын утырту һәм карау чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр» чыгымнар юнәлеше атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- R0340 «Күпьеллык җимеш һәм җиләк агачларын утырту һәм карау чыгымнарының бер өлешен каплауга финанслашыла торган чыгымнар»;

«14 1 03 00000 «Үсемлекчелек, аның продукциясен эшкәртү, үсемлекчелек продукциясе базарлары инфраструктурасын һәм логистика белән тәэмин итүне үстерү кече тармагын кредитлауга дәүләт ярдәме» төп чарасы» максатчан статьясында:

«- 50390 «Федераль бюджет средстволары хисабына, үсемлекчелек, аның продукциясен эшкәртү, үсемлекчелек продукциясе базарлары инфраструктурасын һәм логистика белән тәэмин итүне үстерүгә инвестиция кредитлары (займнар) буенча процент ставкасының бер өлешен каплауга субсидияләр» чыгымнар юнәлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- 50390 Федераль бюджет средстволары хисабына, үсемлекчелек, аның продукциясен эшкәртү, үсемлекчелек продукциясе базарлары инфраструктурасын һәм логистика белән тәэмин итүне үстерүгә инвестиция кредитлары (займнар) буенча процент ставкасының бер өлешен каплауга субсидияләр

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча үсемлекчелек, аның продукциясен эшкәртү, үсемлекчелек продукциясе базарлары инфраструктурасын һәм логистика белән тәэмин итүне үстерүгә инвестиция кредитлары (займнар) буенча процент ставкасының бер өлешен каплауга федераль бюджеттан субсидияләр хисабына хәл ителә.

